


Педагог һәм остаз елында Ульяновск шәһәрендә халык укытучылары съезды һәм Ботенроссия педагогик династияләрнен пленар сессиясе узды. 100 дән артык ин борынгы педагогик династия вәкилләре Ульяновск-та узган пленар сессиядә онлайн һәм офлайн катнаштылар. Шулай ук нәселле педагоглар vз гаиләләрендә буыннан-буынга тапшырыла торган тәжрибә уртаклаша алдылар.      Ботенроссия пленар сессиясе эшендә кондезге форматта Мордовиянен Кадошкино районы Большая Поляна авылыннан Капкаевларнын педагогик династиясе вәкиле, «Большеполянская ООШ» мәктәбе директоры Наиль кызы Светлана Кильдеева катнашты. Ул чыгышында vз гаиләсенен педагогик тарихы турында сойләде. Пленар сессия барышында катнашучыларга онлайн-форматта Россия мәгариф министры Сергей Кравцов морәжәгать итте. Үзенен чыгышында Сергей Кравцов билгеләп vткәнчә: «Кайбер гаиләләрдә буыннан-буынга укытучы хезмәтенә мәхәббәт һәм хормәт бирелә - бу уникаль педагогик династияләр, алар ботен ил буенча 500 дән артык. Мондый гаиләләрнен тарихлары һәркемгә билгеле булырга, vсеп килvче буын, булачак педагоглар очен vрнәк булырга тиеш». Шулай ук сессия кысаларында педагоглар заман vзгәрешләренә һәм чакыруларына һәм традицияләрне саклауга әзерлек турында сойләделәр, буыннар дәвамчанлыгын формалаштыру тәжрибәсе белән уртаклаштылар. Кvпьеллык хезмәте, һонәренә тугрылыгы, педагог һәм остаз елы чараларын гамәлгә ашыруга керткән олеше очен РФ Мәгариф министрлыгынын Рәх-мәт хаты Капкаевлар династиясе варисы Светлана Наиль кызы Кильдеевага тапшырылды.

Светлана Кильдеева Капкаевлар династиясе вәкиле булып тора, анын тарихы XIX гасыр ахырында башлана. Светлана Кильдеева М.Е.Евсевьев исемендәге Мордовия дәvләт педагогия институтынын башлангыч белем бирv педагогикасы һәм методикасы факультетында укый. Ул 23 ел педагогикага багышлый, хәзер туган авылындагы топ гомуми белем бирv мәктәбе директоры булып эшли. Педагогик династиянен гомуми стажы 800 елдан артык.

**Наилә НАСЫРОВА**